ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.06.2022 ел Баулы шәһәре № 118

Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бару тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бару тәртибе (1 нче кушымта);

Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестры формасын (2 нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестрын алып барырга вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасын билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

1 нче кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 24 июнендәге
118 номерлы карыр белән
расланган

Баулы муниципаль районының чыгым
йөкләмәләре реестрын алып бару тәртибе

1. Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестры Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен исәпкә алу һәм аларны үтәү өчен кирәкле Баулы муниципаль районы бюджеты чаралары күләмен билгеләү максатында алып барыла.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр:

Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестры - бюджет планлаштыруы субъектларының чыгым йөкләмәләре реестрлары җыелмасы, шулай ук аңа кушымта итеп бирелә торган, Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре күләмен һәм структурасын характерлый торган җыелма күрсәткечләр;

Бюджет планлаштыруы субъектының чыгым йөкләмәләре реестры - бюджет планлаштыруының әйдәп баручы субъекты Баулы муниципаль районы исеменнән муниципаль хакимият органнары тарафыннан төзелгән, Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре барлыкка килүне күздә тота торган, закон нигезендә бюджет планлаштыруы субъекты бюджеты акчалары, аңа буйсынган учреждениеләр чыгымнарын да кертеп, үтәлергә тиеш шартнамәләр һәм килешүләр (аерым статьялар, пунктлар, пунктлар, норматив хокукый актларның, шартнамәләрнең һәм килешүләрнең абзацлары) җыелма (исемлек), шулай ук, Баулы муниципаль районы бюджеты турындагы карар нигезендә, чираттагы финанс елына Баулы муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр булып торучы аерым мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт учреждениеләренең чыгымнары (тиешле чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары күләмен күрсәтеп).

3. Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестры бердәм мәгълүмат базасыннан гыйбарәт һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

- вәкаләтләр атамасы;

- бюджет классификациясе коды;

- норматив хокукый актлар, шартнамәләр, килешүләр өлешендә акчаларны финанс белән тәэмин итүне һәм тоту тәртибен билгели торган норматив хокукый җайга салу;

- чыгым йөкләмәләрен үтәүгә (хисап финанс елына (план, факт), агымдагы финанс

елына (план), чираттагы финанс елына (фараз), план чорына (ике елга фараз) акча күләме;

- искәрмә.

4. Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестрын төзү максатларында Баулы муниципаль районының барлык чыгым йөкләмәләре түбәндәге төркемнәргә бүленә:

- Баулы муниципаль районының норматив хокукый актларын кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләре, Баулы муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен гамәлгә ашыру кысаларында шартнамәләргә (килешүләр) бәяләмә;

- Баулы муниципаль районының норматив хокукый актларын кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләре, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешендә каралган исемлек буенча шартнамәләргә (килешүләр) бәяләмә;

- Баулы муниципаль районының норматив хокукый актларын кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләре, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү хокукын гамәлгә ашыру кысаларында шартнамәләргә (килешүләр) бәяләмә;

- Баулы муниципаль районының норматив хокукый актларын кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләре, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында шартнамәләргә (килешүләр) бәяләмә;

- Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән тапшырылган, әмма гамәлгә ашырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләре;

- Баулы муниципаль районының норматив хокукый актларын кабул итү, бюджетара трансфертлар бирүне күздә тоткан килешүләр төзү нәтиҗәсендә барлыкка килгән чыгым йөкләмәләре, Баулы муниципаль районы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бюджетара трансфертлар бирүне күздә тоткан килешүләргә бәяләмә.

5. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Баулы муниципаль

районының чыгым йөкләмәләре реестрын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыра.

---

2 нче кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 24 июнендәге
118 номерлы карыр белән
расланган

Форма

Баулы муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестры

<table>
<tr><th rowspan="3">№ п/п</th><th rowspan="3">Чыгым йөкләмәләре вәкаләтләре исеме</th><th rowspan="3">Чыгым йөкләмәләре коды *</th><th colspan="6">Финанс белән тәэмин итүне һәм акчаларны тоту тәртибен билгели торган норматив хокукый җайга салу</th><th rowspan="3">ГРБС Коды</th><th rowspan="3">Бүлекнең коды һәм функциональ классификация бүлекчәсе</th><th rowspan="3">Функциональ классификациянең максатчан маддәсе коды</th><th rowspan="3">Функциональ классификациянең максатчан маддәсе коды</th><th rowspan="3">Дәүләт идарәсе секторының операцияләр коды</th><th colspan="6">Чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен акча күләме, мең сум</th><th rowspan="3">Искәрмә</th></tr>
<tr><th colspan="3">Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, шартнамәләре, килешүләре</th><th colspan="3">Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, шартнамәләре, килешүләре</th><th colspan="2">хисап финанс елы</th><th rowspan="2">Агымдагы финанс ел</th><th rowspan="2">Чираттагы финанс ел</th><th colspan="2">План чоры</th></tr>
<tr><th>Норматив хокукый акт исемнәре һәм реквизитлары</th><th>статьяның, өлешенең, пунктының, пунктчасының, абзацының номер</th><th>үз көченә керү датасы һәм гамәлдә булу вакыты</th><th>Норматив хокукый акт исемнәре һәм реквизитлары</th><th>статьяның, өлешенең, пунктының, пунктчасының, абзацының номер</th><th>үз көченә керү датасы һәм гамәлдә булу вакыты</th><th>Планлаштырылган</th><th>Фактта башкарылган</th><th>финанс елы + 1</th><th>финанс елы + 2</th></tr>
</table>

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ы | | | ы | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |

--------------------------------

* - икенче, өченче һәм дүртенче төркемнәргә караган чыгым йөкләмәләре кодлары беренче төркем буенча чыгым йөкләмәләре кодларына тәңгәл рәвештә формалаша.